**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЧҮРИ-БУРАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2020 ел, 25 май N149

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чүри-Бураш авыл җирлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәнең кайбер пунктларының гамәлдә булуын туктатып тору хакында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм федераль бюджетны үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 1 апрелендәге 103-ФЗ номерлы Федераль законына таянып Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чүри-Бураш авыл җирлеге советы **карар итте:**

1. «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Чүри-Бураш авыл җирлеге советының «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Чүри-Бураш авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 8 ноябрендәге 131 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Чүри-Бураш авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәнең түбәндәге пунктларының гамәлдә булуын 2021 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга:

- 15 статьяның 2 пункты;
- 15 статьяның 3 пункты;
- 27 статьяның 3 пункты;
- 27 статьяның 4 пункты.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Чүри-Бураш авыл җирлегенең мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чүри-Бураш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Чүри-Бураш**
**авыл җирлеге Башлыгы** **И.Р. Мифтахов**